**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ LIV СЕССИЯСЕ**

# КАРАР №93

**Иске Карамалы авылы** **24 нче март 2025 ел**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районың Иске Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иске Карамалы авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә (2 нче кушымта), әлеге карар кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (muslumovo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Иске Карамалы, Түреш, Кубәк, Яңа Карамалы, Карл Либкнехт исемендәге авыллары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә:

Иске Карамалы ав., Кооператив ур., 113А йорт (мәдәният йорты бинасы);
Түреш ав., Урман ур., 30 й. (шәхси йорт);
Кубәк ав., Гвардия ур., 49а йорт (мәчет бинасы);
Яңа Карамалы ав., Бакча ур., 37б йорт (авыл клубы бинасы);
Карл Либкнехт исем. ав., Үзәк урам, 2 йорт (шәхси йорт).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мөслим муниципаль районының

Иске Карамалы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Кәримов

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлеге Советы сессиясе 2025 елның 24 мартындагы 93 номерлы карарына 1 нче кушымта


# СХЕМА

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Иске Карамалы авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органына депутатлар сайлаулар буенча сайлау округлары

| № п/п | сайлау округы исеме, № | сайлау округына керүче торак пунктлар | сайлау округына керүче урамнар исеме | сайлау округына керүче йортлар номерлары | сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Иске Карамалы № 1 | Иске Карамалы авылы | Игенче урамы | тулысынча | 90 |
| 2 | Иске Карамалы № 2 | Иске Карамалы авылы | Яшьләр урамы | тулысынча | 93 |
| 3 | Иске Карамалы № 3 | д. Тюрюш | тулысынча | | 93 |
| | | Иске Карамалы авылы | Кооператив урамы | №№ 1 – 51<br>№№ 2 – 46 | |
| 4 | Иске Карамалы № 4 | Иске Карамалы авылы | Кооператив урамы | №№ 53 – 113<br>№№ 48 – 104 | 100 |
| 5 | Иске Карамалы № 5 | Иске Карамалы авылы | Яр буе урамы | тулысынча | 102 |
| | | | Кооператив урамы | №№ 115 – 121<br>№№ 106 – 126 | |
| | | Күбәк авылы | Гвардия урамы | №№ 1 – 19<br>№№ 2 – 20<br>№№ 86 – 90 | |
| 6 | Күбәк № 6 | Күбәк авылы | Гвардия урамы | №№ 21 – 93А<br>№№ 20 – 84 | 92 |
| 7 | Яңа Карамалы № 7 | Яңа Карамалы авылы | тулысынча | | 95 |

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районы Иске Карамалы авыл җирлеге Советы
сессиясе 2025 елның 24 мартындагы 93 номерлы
карарына 2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы
## Иске Карамалы авыл җирлегенең бермандатлы сайлау округлары схемасының график рәсеме



Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районы Иске Карамалы авыл җирлеге Советы
сессиясе 2025 елның 24 мартындагы 93 номерлы
карарына 3 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы
# Иске Карамалы авыл җирлегенең бермандатлы сайлау округлары схемасының график рәсеме

